# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Тимерче торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

8 апрель 2024 ел № 4

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 6 апрелендә 16.00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, “2024 елда үзара салым кертүгә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә ризалыгыгыз бармы” мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Тимерче торак пунктында яшәүче һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган акчаларны хәл итү өчен түбәндәге эшләргә юнәлдерелде:

а) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тимерче авылына керү юлларын һәм вак таш сатып алу);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 48 (кырык сигез) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 25 (егерме биш) кеше, бу 52%ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 25 (егерме биш) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Тимерче торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда үзара салым акчасын, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Тимерче торак пунктында даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум (бер мең) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Тимерче авылына керү юлларын һәм вак таш сатып алу);

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.Р. Зиннәтуллин